
Бүгенге санда:



Җиңү бәйрәменә һәйкәлләр яңара. 2 бит


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 17 апрель 2015 ел

№ 28 (10557)


**18 апрельгә һава торышы:** алмашынучан болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил көнбатыштан, 3 м/с; температура көндез +9°С, төнлә +3°С

### Җиңү календаре

**22**

**БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ – 9 МАЙГА КАДӘР ШУЛКАДӘР ВАКЫТ КАЛДЫ**

*1945 елның 17 апреле – Рурада немец гаскәрләре капитуляцияләнгән көн. Знче Белоруссия фронтының гаскәрләре дошманның куәтле каршылык күрсәтүе Фишхаузен шәһәрен алдылар.*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### ЧӘЧҮГӘ ЧЫКТЫЛАР

Нурлат игенчеләре республикада беренчеләрдән булып язгы чәчүгә чыктылар. Елдагыча, чәчүне беренче булып "Сәләйманов Ә.И" КФХсы башлап җибәрде. Районның башка хуҗалыклары да чәчүгә старт сызыгында. Берүк вакытта басуларда уҗымнарны һәм күпьеллыкларны өстәмә тукландыру дәвам итә. Кичәге көнгә уҗымнарга 2200, күпьеллыкларга 3000 гектарда өстәмә сый кертелгән.

### ҖӘЙЛӘҮ ЧОРЫ ҖИТТЕ

Шул көннәрдә "Нурлат сөте" хуҗалыгының Югары Нурлат бүлекчәсендә җәйләүгә яшь терлекләрне күчерделәр. "Агромир" СӘ җәмгыятенең Каравыл Тавы бүлекчәсендә дә җәйләү чорына ныклы әзерлек алып баралар. "Агромир"лылар берүк вакытта үзләрендә зона семинар-киңәшмәсе үткәрүгә дә әзерләнә. Ул җәйләү чорына күчү, энергиягә бай азык әзерләү һәм башка көнүзәк темаларга багышланачак.

### КИЧӘГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Бүген, 17 апрельдә 15.00 сәгатьтә шәһәр Мәдәният сараенда "Нурлат йолдызлыгы" исемле әдәби-музыкаль кичә була. Программада җирле шагыйрьләр һәм аларның иҗатлары белән танышу, һәвәскәр артистлар чыгышлары. Бирегә Нурлат рәссамы Рөстәм Хәйретдинов күргәзмәсе эшләячәк, ташламалы шартларда район газетасына язылу оештырылачак.

# Нурлатлылар Президент белән



Автор фотосы

ПАРЛАМЕНТ АКТИВЫ: АЙНАЗ ХӘЙРУЛЛИН, ЛЕНАР ӘҺЛИУЛЛИН, ГӨЛНАЗ ГАЗИЗОВА

**Нурлатлылар Татарстанда яңа оешкан "Президент белән бергә" республика иҗтимагый хәрәкәтенә кушылдылар.**

13 апрельдә Казанда иҗтимагый оешмалар "Без булдырабыз! Без бергә! Мы можем! Мы вместе" форумын үткәрделәр. Анда бездән район Советы каршындагы Яшьләр парламенты рәисе Ленар Әһлиуллин катнашты. Ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр иҗтимагый палатасының Нурлат муниципаль районыннан сайланган әгъзасы да. Бүген Яшьләр парламенты районның 29 инициатив яшь кешесен берләштерә.

– Без республика лидерының тынычлык һәм тотрыклылыкны саклау хакына берләшергә чакыруына кушылдык. Форумда да сүз шул хакта барды. Аның максаты – Президент программаларын һәм инициативаларын хуплау буенча конкрет гамәлләрне тормышка ашыру өчен берләшү иде, – дип сөйли Ленар Фәнилевич. – Яшьләр оешмаларының инициативалары "Президент белән бергә" масштаблы иҗтимагый хәрәкәтенә әверелде.

Инициативаларның берләшүе республиканың 2030 елга кадәр исәпләнгән социаль-икътисади үсеш стратегиясенә дә кулай, форумда бу хакта да сүз булган.

– Татарстан лидеры "Стратегия 2030"ны тасвирлап, аның төп кыйммәте – кеше, дип билгеләп үтте. "Без бергә" иҗтимагый хәрәкәте, Татарстан үсеше өчен мөһим булган перспективалы һәм нәтиҗәле инициативалар эзләү өчен, республика халкын берләштерүгә юнәлдерелгән, – ди Ленар Әһлиуллин.

Район Советы каршындагы Яшьләр парламенты, үз чиратында, яшьләрнең конкрет проблемаларын хәл итүгә йөз тотып эшли. Инде тиздән бу уңайдан аларның эшләре җайга салыначак, чөнки парламентның Халыклар дуслыгы йортында үз почмаклары булачак. Аларның исә күп кенә проблемаларны хәл итү буенча үз планнары да бар.

– Иң актуаль проблемаларның берсе – яшьләрне эшкә урнаштыру. Моны хәл итү өчен без Мәшгульлек үзәге белән килешү төзергә ниятлибез, – дип планнарын уртаклаша парламент рәисе урынбасары Айназ Хәйруллин.

Яшь парламентарийлар уздыручы чаралар да нурлатлыларны эшлекле максатларда берләштерүгә юнәлтелгән. Күптән түгел генә алар саф һавада гомуми зарядка уздырдылар, даими рәвештә экологик акцияләр үткәреп торалар.

– Иң мөһиме – һәркемнең республикабызның бөек мирасына гына түгел, ә аның киләчәгенә дә катнашы барлыгын, моның өчен җаваплы икәнлеген тою. Шуңа да республика лидерының чакыруына кушылып, моны конкрет гамәлләр белән дә ныгыту зарур әле. Чөнки бу безнең республикабыз, үз Татарстаныбыз бит, – ди Ленар Әһлиуллин.

Валентина **ВАФИНА**

Тулырак "Атна вакыйгалары"ннан укыгыз

АКТУАЛЬ

# Әлегә хуҗаларын эзлиләр

**"Халык инвентарьлаштыруы" һәм санитар икеайлык кысаларында хуҗасыз милекләрне ачыклау буенча район комиссиясе иясез участокларны һәм корылмаларны ачыклап, аларны исәпкә кую буенча эш алып бара. Комиссиянең беренче утырышы сишәмбе көнне шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин катнашында узды.**

– Максатыбыз – шәһәрдә тәртип салу, – ди ул. – Ташландык гаражлар, дача участоклары җитәрлек. 90нчы елларда исәпкә алынмыйча калган һәм хәзер ташландык хәлдә булган биналар, хуҗалары күптән вафат булган җирләр дә бар. Бюджетка салым кермәү белән беррәттән, алар шәһәр йөзен дә бозып тора, санитария ягыннан да яхшы түгел. Муниципаль җирләр шәһәр милкендә булырга тиеш.

– Шәһәрдә иң киң таралган кагыйдә бозу – җир участогын тиешле тәртиптә теркәмичә генә үзлектән үзләштерү, - ди Росреестр идарәсенең Нурлат районы начальнигы Татьяна Морозова. – Кайберәүләр үз йорт яннарында транспорт чараларын ремонтлау пунктлары төзиләр, киосклар, чанада гаражлар урнаштыралар, үзлектән бакчаларын зурайталар. Мондый эшләр җирле үзидарә органнары актлары нигезендә генә башкарылырга тиеш. Җир участокларын билгеләнеше буенча кулланмаучылар административ җаваплылыкка тартылачак. Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе Кодексына агымдагы елдан үз көченә кергән үзгәрешләр нигезендә, җиргә кагылышлы законнарны бозган өчен штрафлар артты. Элек җирне рәсмиләштермичә файдаланган өчен 500-1000 сум штраф каралган булса, хәзер 5000 сум һәм аннан да күбрәк.

– Рәсмиләштерү процедурасы җиңел түгел, – ди районның "Җир мөнәсәбәтләре һәм милек палатасы" МУ рәисе Рәмис Шәйхетдинов. – Әмма хуҗасыз җир һәм корылмалар ачыкланып, милек хокукына теркәлеп исәпкә алынырга тиеш.

Иясез объектны ачыклау бер эш булса, аны хуҗасына, я булмаса муниципалитет балансына кую өчен техник документация оформить итәргә, ә аннан Росреестрга заявка бирергә кирәк булачак икән.

Комиссия әгъзалары ярдәмгә килергә әзер. "Максатыбыз халыкка җәза бирү түгел, ә хуҗасыз корылмаларны һәм җирләрне оформить итү мәсьәләсен чишү", - диләр комиссия әгъзалары беравыздан.

Зилия **ӘКСАНОВА**

### ШАЛТЫРАТЫГЫЗ!

**Хуҗасыз җирләрне һәм биналарны оформить итү буенча сорауларны күпфункцияле үзәк белгечләренә 2–06–16 телефоны буенча юлларга мөмкин.**

# ВАКЫТ. ВАКЫЙГА

СӘЯСӘТ



Автор фотосы

## Яшьләрнең үз парламенты бар

**9 апрельдә Нурлат муниципаль районы Советы каршындагы Яшьләр парламентының беренче утырышы узды.**

Тәүге утырышның көн тәртибендә оештыру мәсьәләләре – Яшьләр парламентының составын сайлау, агымдагы елга планны раслау һәм башкалар каралды. Утырышка Нурлат районы башлыгы урынбасары Флюра Ногманова, ТР Дәүсоветы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасының җаваплы секретаре Илдар Суфияров, "Татарстан Республикасының аграр яшьләр берләшмәсе" иҗтимагый төбәк оешмасы рәисе урынбасары Ильмира Сабирҗанова, депутатлар һәм районның авыл җирлекләре башлыклары чакырылган иде.

Парламент әгъзалары тавыш бирү юлы белән Яшьләр парламенты Советын расладылар. Советта яшьләрнең төп эшчәнлек юнәлешләре буенча – хокук мәсьәләләре, хезмәт һәм мәшгульлек, инновацион үсеш, мәгариф, мәдәният, патриотик тәрбия, социаль мәсьәләләр, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше, яшьләр туризмы үсеше комиссияләре эшләячәк. Яңа яшьләр органы составына эшләүче яшьләр белән беррәттән, мәктәп укучылары да керде.

Яшьләр парламенты эшеннән тыш, районда "ТРның Аграр яшьләр берләшмәсе" төбәк иҗтимагый оешмасы бүлегең оештыру да планлаштырыла. Оешма вәкиле Ильмира Сабирҗанова әйтүенчә, мондый берләшмә булдыру Нурлат яшьләренә дәүләт программаларында катнашырга мөмкинлек бирәчәк.

- Яшьләр парламенты – Нурлат районы өчен яңалык, һәм ул район һәм шәһәрдәге балалар һәм яшьләр оешмаларын берләштерүче үзәк булырга тиеш, – дип билгеләп үтте Нурлат районы башлыгы урынбасары Флюра Ногманова.

Гөлназ ГАЗИЗОВА

ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР ЕЛЫ

## Үсентеләрне әзерләделәр дә, утырттылар да

**2нче мәктәп укучылары агачлар утырту сезонын Җиңүнең 70 еллыгы хөрмәтенә истәлек аллеясе салудан башладылар.**

Кайчандыр бу мәктәп зур тирәкләр белән томаланып тора иде. Вакыт узу белән агачлар картайды, кипте һәм аларны кисеп алырга туры килде. Һәм, ниһаять, әлеге урында тиздән янә агачлар шаулый башлар, мөгаен. Бу эшкә укучылар алынды, алар районның табигатьне саклау инспекторы Рөстәм Ногманов инициативасы белән үсентеләрне дә үзләре әзерләде.

– Без Җиңүнең 70 еллыгына аллея утыртабыз, – ди экологик түгәрәк җитәкчесе Елена Сидорова. – Парклар һәм скверлар елында символик гамәл бу. Бүген 13 үсенте утыртабыз, укучылар исә 90лап үсенте әзерләде, алар артык булмаячак, таратачакбыз.

8Б сыйныф укучылары тырышып чокырлар казыды, ә аннан 7Б сыйныфы үсентеләрне утыртты, су сиптеләр. "Бу районндагы баш эколог проектының гамәли өлеше", – диде 8А сыйныфы укучысы Данил Галкин. Ул сыйныфташы Регина Лисюкова белән "Нурлатны шәһәр-бакчага әверелдерик" проекты өстендә эшли. "Шәһәребездә яхшы экология булуын, күп яшел үсентеләр үсеп утыруын телибез. Шуңа күрә барлык нурлатлыларны да акциябездә катнашырга чакырабыз", – диләр балалар. Рөстәм Ногманов әйтүенчә, 3нче мәктәптә дә шундый проект гамәлгә ашырыла икән, анда да укучылар үсентеләрне үзләре әзерләгән.

– Алар белән үсентеләрне 25 апрель, агач утырту көнендә утыртачакбыз, – диде эколог һәм үсентеләр булдыру проектының дәвамлы булачагын да әйтте.

Сирень СӘМӘРХАНОВА



Автор фотосы

ТИЗДӘН БУ ҮСЕНТЕ НЫК АГАЧ БУЛЫП ҮСӘР

КӨН КАДАГЫНДА

## Хокук бозучыларны күздән югалтмаска

**Районда алкоголь продукциясенең легаль әйләнеше сизелерлек кимегән. Бу хакта районда алкоголь продукциясе әйләнеше өлкәсендә хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау буенча ведомствоара комиссия утырышында әйтелде.**

Бу – башка актуаль мәсьәләләр кебек үк бик мөһим тема, дип ассызыклады район башлыгы Равил Кузюров утырышны ачканда. Көн тәртибенә берничә мәсьәлә чыгарылган иде. Район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Руслан Морадыймов ведомствоара комиссиянең һәм сәүдә предприятиеләрен тикшерү буенча мобиль төркемнең эше турында мәгълүмат җиткерде.

– Өч ай эчендә легаль алкоголь продукциясен реализацияләү шәһәрдә 13, авылларда 21 процентка кимегән, – диде ул һәм узган утырышта авыл җирлекләре башлыкларына урыннарда җәмәгатьчелек белән тиешле эш башкарылырга кушылганлыгын да искә төшерде. Чөнки авылда берәрсенең ялган һәм хәтта куркыныч спиртлы продукция белән сату итүен сизми мөмкин түгел бит. Районда быелның өч ае эчендә ялган аракы һәм спиртлы продукция сату буенча ачыкланган фактлар турында мәгълүматны Россия МВДсының Нурлат районы бүлеге начальнигы Хафиз Нургатин җиткерде. Асылда ул март-та алкогольне законсыз сату факты буенча җинаять эше ачылуын әйтте.

Утырыш эшендә Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чистай территориаль органы начальнигы Александр Саунин да катнашты. Ул уздырылган тикшерүләрнең нәтиҗәләре белән таныштырды.

– Районда аклоголь продукциясенең легаль әйләнеше сизелерлек кимегән, – диде ул, һәм моны өйдә җитештерелгән ялган продукция сату белән бәйләде. Бу уңайдан утырышта җирлекләр башлыкларына полиция участковыйлары белән берләләп ялган продукция сату фактларын ачыклау буенча тиешле эш алып барырга, ә законсыз сәүдә белән шөгыльләнүчеләрне контрольгә алып, җавапка тартырга кушылды.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

САН

**Районның стационар сәүдә һәм алкоголь продукциясе сату ноктасы булмаган 30дан артык авылында күчмә сәүдә оештырылган.**

## КОРРЕСПОНДЕНТЛАР ПУНКТЫ БУЛДЫРЫЛДЫ

Республикада Бөек Ватан сугышы темасына багышлап оештырылган Интернет-музейны материаллар белән тулыландыру өчен Нурлат районы башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә корреспондентлар пункты булдырылды.13 апрельдә аның рәисе, район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Әлфия Галәветдинова корпунктның оештыру утырышын үткәрде. Корпункт Кама арьягы һәм Нурлат шәһәре төбәк музее каршында эшләячәк, аның администраторы итеп музей директоры Флера Морзаханова сайланды. Аның составына массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, мәгариф, мәдәният хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре һ.б.лар кертелде. Интернет-музей ачык булачак – Татарстанлыларның җиңүгә керткән өлешен мөмкин кадәр тулырак күрсәтәчәк мәгълүмати база белән бөтен республика халкы таныша алачак. Корпункт исә безнең районнан сугыш темасын яктырткан, халкыбызның сугышчан батырлыгын һәм тылдагы фидакарьлеген күрсәткән материалларны җибәреп тору белән бергә Бөек Ватан сугышына кагылышлы сораулар буенча гражданнарны да кабул итәргә тиеш була. Әлбәттә, әлеге мәгълүматларны мәдәни-белем бирү эшчәнлегендә куллану зарур. Ә мәгълүматларны ничек һәм кая тапшырасы? Бусына аңлатманы Флера Җамаловна бик гади бирде.

– Һәр язманы, видеоматериалны район корпунктына, ягъни безгә юлларга кирәк булачак. Корпункт атнага бер тапкыр Нурлат районы буенча материалларны Интернет-музейга тапшырачак. Музей аша нурлатлылар үзләренең сугышта хәбәрсез югалган туганнары турында мәгълүмат та сората яки сугышта катнашучылар турында язмалар урнаштыра да алачаклар, – диде администратор. Корпунктка үз материалларын белән беренче мөрәҗәгать итүчеләр бар икән инде. Ә җентекләрәк мәгълүматны 2-29-12, 2-10-61 телефоннары аша белешә аласыз.

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

# КӨН АРТЫННАН КӨН.

ҖИҢЕЛ ПАР БЕЛӘН!

## Тәнгә – сихәт, җанга ял бирә




Автор фотосы

**Шәһәр муниципаль мунчасы ачылганнан бирле меңгә якын кеше аның хезмәтләреннән файдаланырга өлгергән.**

Гомер-гомергә мунча санитар-гигиеник процедуралар үтәү урыны булу белән беррәттән, кеше организмы өчен чистарыну һәм сәламәтләндерү ягыннан да зур роль уйный. Аның шифасы санап бетергесез: матдәләр алмашы яхшыра, сулыш алу органнары, йөрәк-кан әйләнеше системалары һәм бөерләр яхшырак эшли башлый. Бүген шәһәр халкына хезмәт күрсәтүче 4 мунча бар. Якын арада шикәрчеләр бистәсендәге мунча да ачылачак. Әлеге шәхси мунчада хәзер тулы көченә ремонт эшләре бара. Хуҗалары аны июнь азагында өлгертергә җыена. Мунча җәһәтеннән шәһәрдә проблема булмаска охшаган. Яңа җәмәгать мунчасы исә өлкән буын күңеленә аеруча хуш килгән.

– Мондый мунча бик кирәк иде, - ди нурлатлы Надежда Прокопьева. – Безнең өчен бу бәяләп бетергесез бүләк булды. Аеруча "Яшьлек" микрорайонында кайнар сулары булмаган кешеләр өчен бик әйбәт. Мунчаның режимы да бик җайлы. Халыкка мондый мөмкинлекләр тудырганнары өчен район җитәкчеләренә рәхмәт.

"Мунча чабындыра да, сәламәтлек тә бүләк итә", - ди халык. 7 кешегә эш урыны биргән учреждениедә бер үк вакытта өч залда 20 кеше юынып, сихәт ала. Өстәвенә, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен аерым кабина эшли. Моннан тыш, массаж, чәчтараш хезмәтләре дә күрсәтелә.

– Бездә Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен юыну бушлай булса, пенсионер, инвалидларга һәм 7 яшькәчә балаларга ташламалар каралган. Моннан тыш, алга таба гаиләләр өчен аерым юыну урыны булдыру өстендә эш алып барабыз. Гомумән, халыкның төрле катламына кулай булсын дип эшләргә тырышабыз, – ди мунча мөдире Гөлнур Ибатуллина.

– Шәһәрнең ике мунчасында булганым бар, әмма яңа ачылганы хезмәт күрсәтү буенча лидер, - ди Фәрит ага Фәттахов. – Без, өлкәннәргә ял итү, аралашу урыны да әле ул. Бирәдә кешеләргә мөнәсәбәт тә бик ипле. Телисең икән, кайнар чәйгә кадәр бирәләр. Бүгенге заманча җәмәгать мунчасы кыйммәтле сауналардан бер җире белән дә калышмый.

Мунча коллективы нурлатлылар өчен уңайлыкларны тагын да арттырырга планлаштыра. Шуларның берсе – территорияне яшелләндерел, ял зонасы булдыру.

Зилия ӘКСАНОВА

СПОРТ. СӘЛАМӘТЛЕК

## Гаиләнең бердәмлеге сынауларда беленә

**184 килограмм һәм 60 яшь, 143 килограмм – 91 яшь, 169 килограмм – 99 яшь... Балалар-үсмерләр спорт мәктәбендә узган "Әти, әни һәм мин – спорт сөюче гаилә" ярышларын оештыручылар быел әнә шулай, һәр команданың гомуми авырлыгын һәм яшен исәпләп чыгарганнар иде.**

Спорт мәктәбе соңгы елларда үзенчәлекле чаралар уздырырга ярыйсы ук хирысланып китте.

– "Әти, әни һәм мин – спорт сөюче гаилә" ярышларын өченче тапкыр уздырабыз инде, һәм һәр елны аңа үзенчәлекле төсмер бирергә тырышабыз, быел рекордлы күрсәткечкә дә ирештек, – ди мәктәп директоры Фәнил Гайнуллин. Директорның "рекорд" дигәе командаларның шактый артуына бәйле иде. Быелгы ярышларда Булатовлар, Тайбулатовлар, Калуковлар, Кирисовлар, Бикташевлар, Шароновлар, Шәйхетдиновлар, Корниловлар һәм Икрамовлар гаиләләреннән торган тугыз команда көч сынашты. Бу юлы оештыручылар авыллардагы филиалларын да җәлеп иткәннәр. Әнә, Шәйхетдиновлар Чулпаннан килгәннәр. "Улыбыз спорт мәктәбенең үзебез авылдагы филиалында шөгыльләнә. Чакыруны сөенеп кабул иттек, барлык ярышлар да бик ошады", – диләр Шәйхетдиновлар.

"Без бүген бала чагыбызга кайткан сыман булдык, скакалкада да рәхәтләнеп сикердек, туп белән дә уйнадык. Гомумән, мондый ярышлар гаиләне берләштерүче чара ул", – дип саный Бикташевлар. Ә катнашучы гаиләләргә тәкъдим ителгән сынаулар, заманча әйтсәк, креативлыклары белән аерылып тордылар: командаларга "хат ташучы" булырга да, ластылар киеп "су астында йөзәргә", әти-әниләргә балаларын күтәреп йөгерергә дә туры килде. Шул рәвешле, "Күңелле стартлар" форматында үткән ярышларда гаиләләр ун төрле сынау уздылар. Нәтиҗәдә, Нурлаттан Корниловлар гаиләсе җиңүче булып танылды. Бикташевлар – II, Иске Чаллыдан килгән Шароновлар III урыннар алдылар. Спорт мәктәбе җитәкчелеге исә калган гаиләләрне дә төрле номинацияләр буенча бүләкләде.



Автор фотосы

ҖИҢҮЧЕ КОМАНДА – КОРНИЛОВЛАР

## Идел буе пәһлеваннары бил алышты

**Шул көннәрдә Димитровград шәһәрендә Идел буе шәһәрләре арасында милли көрәш буенча Бөтенроссия турниры үтте. Анда Нурлат спортчылары да үз осталыкларын күрсәтеп кайттылар.**

Шул рәвешле, "Нурлатнефть" идарәсе хезмәткәре Алмаз Мостафин үз үлчәү категориясендә II урын алды. Руслан Әбделманов һәм аграр техникум студентлары Ранис Тәмаев белән Адель Минвәлиев III урыннар белән кайттылар. "Бу бәйге ундүртенче тапкыр уздырылды инде, анда быел да Идел буе федераль округының 9 шәһәреннән көчле көрәшчеләр җыелган иде", – ди егетләрнең остазлары, ДЮСШ тренеры Раил Рәхмәтуллин.

Илназ МӨБАРӘКШИН

ХӘБӘРЛ…

### ВЕТЕРАННАРГА – СО…

**Пенсия фондының Нурлат… идарәсендә ветераннарга со… башладылар.**

7000 сум күләмендәге түләү… инвалидлары һәм ветеранна… сугышы чорында фашистлар һ… ры тарафыннан булдырылга… һәм башка мәҗбүрилән тоту у… булганнар, Финляндия һәм Япо… сугышларында үлеп калган хәрб… гышыннан кайткач вафат булу… чак. Андыйлар районда 376 кеш…

Моннан тыш, 3000 сум күләм… 1941 елның 22 июненнән 1945… айдан артыграк эшләгәннәргә (… купацияләнгән территорияләре… мичә); Бөек Ватан сугышы чор… ләре өчен СССР орденнары… бүләкләнгән затларга, шулай… герлары, төрмәләре һәм гетто… балигъ булмаганнарга бирелә… түләүне 1017 кеше алачак.

- Пенсия фонды тарафыннан б… күләмдә финансланды, һәм ал… лык пенсия алучылар да пенсия… клар, - ди идарә начальнигы Ру…

### ЧӘКЧӘК ПЕШЕРЕР…

Тиздән район хатын-кызлары… ген-лаборант булып эшләүче… чәкчәк пешерү серләренә өйрә… лары. Эш шунда: " Ак калфак… тын-кызлары җәмгыяте һәм Бөт… башкарма комитеты оештыра т… безнең районнан нәкъ менә Зе… апрельдә үтүче әлеге бәйрәмд… мастер-класс та бирәчәкләр. Яруллинаны юллаулары тикма… ның иң актив әгъзаларыннан бу… аш-суга ятып тора, өч кыз эни… да татар милли гореф-гадәтлә…

– Казаннан кайткач, ул үз өйр… рыбызга да бик теләп җиткерер… ның җирле оешмасы рәисе Фәү…

### ВЕТЕРАННА…

Үзәк китапханәнең хокукый… "Онытмыйбыз! Горурланабыз! … блика патриотик акциясендә кат…

Бу акцияне Җиңү көненә ба… сукырлар һәм начар күрүчеләр … игълан иткән иде. Аның кысалар… булдыру ниятләнә, ул киң җәма… ярлар нәтиҗәсендә сукырайг… мәүче тыл хезмәтчәннәренең … ныштыруны һәм начар күрүче т… лы батырлыкларын мәңгеләште… ельязмага Нурлат ветераннары… лар кертеләчәк.

### КИТАП СӨЮЧ…

Үзәк китапханәнең яшь укучы… Какайкиннар хәрби тематика… ча "Алар Ватан өчен сугышт… иҗат эшләре конкурсында катн… ге күрү буенча инвалид балал… Какайкиннар китапханәнең хоку… ярдәме белән Валерий Воск… Тани Савичевой" һәм "На проры… эшләре ясаганнар.

### ТИК…

15-30 апрельдә 73нче янгын час… "Нурлатнефть", "Татнефтеотдача… ларында рейдлар узачак. Аның б… шы су тәэмин ителеше чыганакл… кы яктагы) һәм автомат янгын … тозеклекләре тикшереләчәк.

Николай Н…

МӘГАРИФ

# Язын – каен бөресе, көзен - миләш

**Язгы каникуллар чорында район укучылары тик ятмады – күпчелек мәктәп коллективлары агач бөреләре җыю белән мәшгуль булдылар.**

Агач бөресе белән нишлиләр икән дияргә кайберәүләр. Ә кемнәрдер пионер булып, дару үләннәре җыюда ярышуларын исенә төшерер. Ул чагында дару үләннәре җыю мәктәпләр өчен гадәти эш саналган бит. Хәзер исә республика мәктәпләрендә Татарстан Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннеханов кушуы буенча яңадан әлеге традиция кайтты, һәм районнарга дару-техник чимал әзерләү буенча исемлек һәм план җиткерелде.

- Исемлектә 27 төрдә үлән һәм җиләк-җимеш бар. Мәсәлән, район укучыларына 11 килограммнан артыграк каен бөресе, җир җиләге, балан, юкә, үги ана яфрагы, 68 килограмм мәтрүшкә һәм сары мәтрүшкә, 170 кг. кара миләш, 228 кг. гөлҗимеш һәм башка үләннәр җыярга диган план җиткерелде, - ди район мәгариф бүлеге начальнигы Линар Маняпов. – Без планнан чыгып район мәктәпләренә бирем бүлдек. Язгы каникуллар чорында мәктәпләр бу эшне башлап та җибәрделәр инде.

Бу көннәрдә мәгариф идарәсендә бөреләр җыю буенча беренче нәтиҗәләрне дә ясый башладылар. Район мәгариф бүлеге методисты Любовь Ефимова әйтүенчә, планны иң беренчеләрдән булып Колбай Мораса һәм Урта Камышлы мәктәпләре үтәгән икән. 400әр грамм киптерелгән каен һәм нарат бөреләрен алар китереп тә тапшырганнар инде.

- Бөре җыюның үз вакыты бар. Аларны сок бүленеп чыкканчы җыя башларга кирәк, - дип үзләрендә эшне оештыррлары белән таныштыра Колбай Мораса мәктәбе директорының уку-укыту эшләре буенча урынбасары Розалия Хәснетдинова. – Шөкер, урман янәшәдә генә. Мәктәбебез укытучысы Фалис Сабиров Кычытканлыдан килеп эшли, ул каен ботакларын юл уңаенда кисәргә дип әзерләнгән участоклардан ала килде. Ботакларны тиешле таләпләр буенча киптердек һәм мәктәп укучылары хезмәт дәресләрендә дә, дәресләрдән соң калып та ботаклардан бөреләрен чүпләделәр. Бу эш мәктәп укытучысы Рәмзия Галиуллина җитәкчелегендә алып барылды.



КОЛБАЙ МОРАСА МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫ КАЕН БӨРЕЛӘРЕН ДӘРЕСЛӘРДӘН СОҢ ДА КАЛЫП ҖЫЙГАН.

Каен бөресен шулай укучылар көче белән җыйсалар, нарат бөреләре җыю башлыча мәктәп укытучылары җилкәсенә төшкән. Моның өчен күмәкләшеп урманга барганнар укытучылар.

- Бөре җыюга ике атналап вакыт китте. Тырыша торгач, тиешлесеннән артыгын да җыйганбыз әле. Башка дару үләннәре җыюда да шулай актив катнашырга җыенабыз, җәен балаларны бу эшкә хезмәт чиреген җәлеп итәргә мөмкин, - диләр Колбай Мораса укытучылары.

Сүз дә юк, урманы янәшәдә генә булган авыл мәктәпләре өчен бу эш әллә ни авырлык тудырмас та анысы. Шәһәр мәктәпләре, урманнан ерак урнашкан авыллар бар бит әле. Алар хәлдән ничек чыга? Чөнки дару үләннәре, файдалы җимешләрне шәһәр урамнарыннан, юл читләреннән җыярга ярамый бит.

- Баштa мәктәптә сыйныф җитәкчеләрен, укучыларны җыеп, дару үләннәре, аларның файдалы үзлекләре, җыю вакыты белән таныштырдык, аңгәмәләр үткәрдек, - ди шәһәрнең 9нчы мәктәбе биология укытучысы Людмила Парукова. – Әлбәттә, һәр сыйныфка нинди дару үләне, җиләк-җимеш җыярга кирәклеге дә җиткерелде. Дару үләннәре җыйганда табигатьне саклау турында да онытып җибәрергә ярамый, болар хакында да аңлату эшләре алып барылды. Соңыннан сыйныф җитәкчеләре бу хакта ата-аналарга да җиткерделәр. Чөнки шәһәр җирендә бу эшне ата-аналар ярдәменнән башка гына башкарып чыгып булмаячак. Укытучылар, укучылар һәм ата-аналарның уртак шөгыле булачак бу.

Укытучы әйтүенчә, мәктәптә дару үләннәре җыю октябрь азагына кадәр дәвам итәчәк икән әле. Биология укытучысы буларак, бу эшнең файдалы якларын да күрергә өлгергән – укучылар табигать кочагында ешрак булып, дару үләннәрен танырга өйрәнәчәк, аларның файдалы үзлекләреннән хәбәрдар булачаклар бит.

Ә менә мәгариф бүлеге начальнигы балалар җыйган дару үләннәре өчен алга таба билгеле бер күләмдә акча түләү күздә тотылуын да әйтә. Мәктәпләрдән җыелган чималны урнаштыру хакында да уйланалар. Республикада мәктәп балалары җыйган дару үләннәрен нигездә кулланучылар берләге оешмалары кабул итсә, Нурлатта ул әле оешу стадиясендә генә бит. Шулай да мәктәпләрнең хезмәте әрәм булмас, район үзәк даруханәсендә дә, санаторийларда да аларга ихтыяҗ булачак, диләр мәгариф бүлегендә. Дару үләннәрен каяндыр читтән китерүләрен көтеп ятканчы, үз урманнарыбызда үстерелгән экологик чиста чималны файдалану аларга да отышлырак булачак бит.

Ә мәктәпләрдә балалар танышасы чираттагы дару үләне үги ана яфрагы булырдыр, мөгаен. Аны җыю май азагы, июнь башларына планлаштырыла.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

## КЫСКАЧА

### БАЛАЛАР РӘСЕМ ЯСЫЙ

Бу көннәрдә район һәм шәһәр мәгариф учреждениеләрендә "Бердәм Россия" партиясенең Татарстан төбәк бүлеге игълан иткән "Балалар илне рәсемгә төшерә" IX республика конкурсының беренче этабы дәвам итә. Быел конкурс Җиңүнең 70 еллыгына, Парклар һәм скверлар елына һәм юл хәрәкәте иминлеге, юлларда балалар травматизмын профилактикалау темаларына багышлап үткәрелә. Партиянең җирле бүлекчәсендә район этабы җиңүчеләрен 12 майга кадәр билгеләячәкләр, ә республика буенча җиңүчеләрне 1 июнь – Балаларны халыкара яклау көнендә игълан итәчәкләр.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

### ХОКУКЫЙ ЯРДӘМ БИРӘЛӘР

Район мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы әгъзалары районның һәр мәгариф һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә хокукый консультацияләр үткәрәләр. Шундый чараларның берсе коррекцияләүче интернат-мәктәптә узды.

### ҖИТӘКЧЕЛӘР БЕЛЕМ КҮТӘРӘ

Районның барлык мәгариф һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре "Мәгарифтә менеджмент" укулары узачак. Җитәкчеләрнең һөнәри компетентлыгын арттыруга юнәлтелгән укуларны бүгенге көндә барлыгы 54 кеше уза. Аларга программаны Икътисад, идарә итү һәм хокук университеты (Казан) белгечләре укыта.

Зилия ӘКСАНОВА

## АКЦИЯ ДӘВАМ ИТӘ

10 апрельдә „Мин татарча сөйләшәм" акциясен шәһәрнең 1нче мәктәбе оештырды. Татарстан күләмендә үткәрелә торган акция кысаларында күп төрле чаралар үткәрелде: "Мин татарча сөйләшәм" исеме астында газеталар чыгарылды, укучылар тел турында шигырьләр өйрәнделәр, буклетлар, шарлар, акция логотиплары, сүзлекләр эшләнде һәм халыкка үзенчәлекле бүләкләр - Татарстан байрагы рәсеме төшерелгән магнитлар таратылды. Үткәрү урыны итеп исә мәктәп һәм Нурлатның ял паркы сайланды. Юкка гына түгел, чөнки анда бу көнне шәһәребезнең төрле оешмалары ГТО нормативларын тапшырды бит, һәм шунда катнашучылар арасында буклетлар, магнитлар таратылды.

Фәридә НӘБИУЛЛИНА, татар теле һәм әдәбияты методик берләшмәсе җитәкчесе.

***

Якушкино урта мәктәбенә укучылар 6 авылдан йөреп укыйлар. Билгеле инде, күпчелек укучы чуваш милләтеннән. Шуңа да карамастан, Татарстанның барлык укучылары белән берлектә без – чуваш балалары да татар телен өйрәнәбез. Телне өйрәнүгә кызыксындыру уяту өчен безнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары төрледән-төрле чаралар,конкурслар, ярышлар үткәрәләр. Районреспублика күләмендәге олимпиада, конкурслар, конференцияләрдә яулаган призлы урыннар – күмәк хезмәтебез нәтиҗәсе. Менә әле дә республика күләмендә үткәрелүче "Мин татарча сөйләшәм" акциясенә кушылдык . Чарага авыл халкы да теләп кушылды. Башлангыч сыйныф укучылары шигырь- җырда осталыкларын күрсәттеләр, югары сыйныф укучылары күңелле әңгәмәләр кордылар. Укытучыларыбыз да татар телендә сорауларга җавап бирделәр. Ә инде рус теле һәм әдәбияты укытучысы Елена Колесникова татарча шигырь сөйләп, ә Сергей Семенов "Туган тел"не җырлап шаккатырдылар. 9 нчы сыйныф укучысы Руслан Мостафин үзе иҗат иткән рэп стилендәге җырын башкарды. Кыскасы, беркем дә читтә калмады. Ә 9нчы сыйныф укучылары Константин Матвеев һәм Глеб Акмуллин фильм ясаганнар иде.

Надежда АРТЕМЬЕВА, мәктәпнең X сыйныф укучысы

## УҢЫШЛЫ КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

**10 апрельдә Чистайда узган "Фәннәр канатында" дип аталган III фәнни-гамәли конференциядә Нурлаттан да 11 укучы катнашты. КНИТУ-КАИның "Восток" Чистай филиалы уздырган чара 11 юнәлештә узды. Конференциядән укучылар призлы урыннар белән кайттылар.**

"География һәм экология" секциясендә Мария Капитонова, Юлия Тарасова (Андреевка мәктәбе укучылары) II һәм III урыннар яуладылар. "Биология"дә Язилә Мөхәммәтова (гимназия) II урынны алды. "Физика"да гимназиядән Алмаз Фәхретдинов – I, Инсаф Гайнуллин III урыннарга ия булдылар. "Инглиз теле" секциясендә Рузилә Шәфыйгуллина, Валентина Семенова һәм Юлия Шувалова (Иске Чаллы) II, III урыннар алды. Техникум студентлары Фидаил Фәйзуллин һәм Иван Малайрәу да үз юнәлешләрендә II, III урыннар белән кайттылар.

***

**11 апрельдә үткән IX "Безнең мирас" фәнни-гамәли конференциясендә Нурлат гимназиясеннән ике укучы уңышлы чыгыш ясады.**

"Математика. Физика. Информатика" секциясендә катнашкан 15 тикшеренү һәм проект эшләре арасында 9нчы сыйныф укучысы Инсаф Гайнуллинның (җитәкчеләре Фәнис Газзов һәм Хәлим Әлимов) эше I дәрәҗә диплом белән бәяләнде. "Инглиз теле" юнәлеше буенча чыгыш ясаган V сыйныф укучысы Дарина Пайгерчева (Жанна Сандимирова) II урын белән кайтты.

Хәлим ӘЛИМОВ, гимназия укытучысы

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Үрнәк авылында туып, хәзерге вакытта **Нурлат шәһәрендә яшәүче** кызыбыз, сеңлебез **Гөлназ Вәлимхәмәт кызы Абдуллинаны** юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз.

Туган көнең-юбилееӊ белән
Чын күңелдән сине
котлыйбыз,
Сәламәтлек, шатлык-
куанычлар,
Күңел тынычлыгы телибез.
Юлларыңа ак бәхетләр яусын,
Шатлык балкып торсын
йөзеңдә,
Кайгы-хәсрәт баш
очыңнан узсын –
Шул теләкләр бездән үзеңә.

**Иң изге теләкләр белән этиең Вәлимхәмәт, әниең Фәрдәния, абыең, апаң, туганнарың.**

**Нурлат шәһәрендә** яшәүче кадерле киленебез **Ләйсән Билалованы** юбилее белән котлыйбыз!

Сабыр да син, гади,
кешелекле,
Кылган эшең – бары изгелек,
Шатлыкларда үтсен
синең көннәр,
Бәхетләрең булсын гомерлек.
Сәламәт бул, озак яшә,
Кайгы-хәсрәт күрмә син,
Гомер юлың якты булсын,
Яшәү дәртең сүнмәсен.

**Иң изге теләкләр белән этиең Валерий, әниең Роза, тормыш иптәшең Марсель, улың Эмиль, Гыйззәтуллиннар, Мөхәммәтҗановлар гаиләләре.**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*4 фатирлы йортта 3 бүлмәле фатир. Т. 8-927-474-46-16.
*дом. Варианты. Т. 8-937-283-86-00.
*дом жилой. Т. 8-927-462-17-01.
*дом или обмен. Т. 8-919-684-40-03.
*дом в с. Тюрнясево. Т. 8-927-435-12-10.
*двухуровневый двухквартирный дом (ветлечебница) на участке 13 соток. Т. 8-927-421-12-38.
*новый дом без отделки, ул. Рябиновая. Т. 8-927-406-17-05.
*квартиры, нежилые помещения, коммерческая недвижимость, дома. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.
*продается дом по ул. Мугинова. Т. 8-987-421-39-97.
*продается дом д. Степное Озеро. Т. 8-927-041-39-93.
*магазин „Калейдоскоп" продуктовый рынок, собственность. Т. 8-927-049-26-51.
*дом в дер. Курманаево. Т. 8-937-616-45-84.
*1-комнатная малосемейка, мкр. Яшлек, 550000 руб. Т.: 8-927-403-91-42, 8-927-245-66-78.
*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 9, 3 этаж. Т. 8-937-003-36-39.
*дом, ул. Михеева. Т. 8-937-774-01-32.
*2-комнатная квартира с мебелью, мкр. Яшлек, 3 этаж. Т. 8-927-435-98-23.
*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 9, 3 этаж. Т. 8-937-003-36-39.
*1-комнатная квартира, ул. Тимерзянова. Т. 8-937-284-02-92.
*дом, Чулпаново. Т. 8-927-249-00-75.
*жилой дом, д. Фомкино, ул. Школьная, 47 кв.м, 210 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*старый дом, ул. Гоголя, 10, 120 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*новая 2-комнатная квартира, ул. Кариева, 2 этаж, 51 кв.м, 1330 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*ветхий дом, участок, ул. Гоголя, 10, 120 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, участок, ул. Гоголя, 34, 250 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, ул. Гиматдинова. Т. 8-937-621-78-05.
*дом, ул. Лобачевского, 50. Т. 2-04-04.
*1-комнатная малосемейка. Т. 8-927-498-05-49.
*3-комнатная квартира на с/з. Т. 8-937-283-18-83.
*магазин 400 кв.м по ул. Дружбы, 30. Т. 8-917-251-93-15.
*дом, ул. Декабристов. Т. 2-87-36.
*гараж, недорого. Т. 8-927-246-85-25.
***однокомнатные квартиры**: ул. Школьная, 26, 3 этаж, 750000 руб.; ул. Советская, ремонт, 3 этаж; ул. Циолковского, 32 кв.м; **2-комнатная квартира**, ул. Нурлатская, 18; **дом 2-этажный,** ул. Тукая; **гараж** во дворе ул. К.Маркса, 1. Т. 8-937-600-47-73 (Алсу).

## АВТОТРАНСПОРТ

*„Лада приора", 2013 г.в., белого цвета. Т. 8-927-406-73-21.
*«КамАЗ-55111», самосвал, 1992 г/в. Т. 8-927-675-63-85.
*«Тойота Королла», 2008 г/в, в отличном состоянии. Т. 8-937-521-05-55.
*«ВАЗ-2115», 2008 г/в. Т. 8-937-003-89-86.
*«ВАЗ-2106», 2001 г/в, в хорошем состоянии. Т. 8-927-441-08-00.
*«ВАЗ-2112», 2006 г/в. Т. 8-937-770-11-01.
*«Приора», 2013 г/в, все есть. Т. 8-937-577-52-22.
*«ВАЗ-21099», 2002 г/в, срочно. Т. 8-937-285-51-76.
*«DAEWOO NEXIA», 2010 г/в, автозапуск, идеальное состояние, 205000 руб., торг. Т. 8-927-48-000-74.
*«Лада Калина». Т. 8-929-723-02-06.
*срочно «ВАЗ-2114», 2010 г/в, суперавто. Т. 8-927-675-57-55.
*«ВАЗ-2110», 1997 г/в, 35000. Т. 8-927-246-85-25.

## ДРУГОЕ

***ШИКӘР КОМЫ-2250, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.**
*ПГС, песок, чернозем, перегной, щебень. Т. 8-937-297-08-08.
*Ком, ПГС, елга ташы, вак таш. Т. 8-927-244-11-33.
*Костер, люцерна орлыклары. Т. 8-927-470-39-02.

**КАМЫШЛЫ ИНКУБАТОРЫ**
**тәүлеклек бройлерларга заявкалар кабул итә.**
**8-937-620-80-30 (Румия), 4-35-47 (өй).**

*ПГС, ком. Т. 8-927-424-02-83.
*ПГС, песок, кольца разного диаметра. Т. 8-937-28-62-082.
*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-47-17.
*ПГС, песок, буткамень. Т: 8-927-247-27-37.
*керамзит-керамблоки. Доставка. Т. 8-927-247-85-89.
*пчелосемьи. Т. 8-937-770-46-59.
*песок, ПГС по 15 т. Т. 8-927-405-76-08.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*плиты перекрытия, блоки фундаментные, цемент. Т. 8-960-822-72-75.
*ПГС, дрова колотые. Т. 8-937-617-11-21.
***доски (осина, сосна), брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.**
*пчелосемьи на высадку, печь на отработке, печь на газу, ворота гаражные. Т. 8-919-685-93-14.
*сено, солома, телята мясной симментальской породы, недорого. Доставка бесплатно. Т.: 8-960-396-77-71, 8-937-343-80-22.
*пчелы с ульями. Т.: 8-927-427-79-70, 8-927-409-76-18.
*песок, ПГС. Т. 8-937-283-70-69.
*продаются запчасти на Оку. Т. 8-927-412-39-39.
*пчелосемьи. Т. 8-927-249-00-68.
*коляска-трансформер голубого цвета, недорого. Т. 8-927-248-84-46.
*бычки (молодняк) с доставкой. Т. 8-927-870-49-62.
*семена костер, люцерны. Т. 8-927-470-39-02.
*куры-молодки. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.
*новая ванна, дешево. Т. 8-9270-35-72-68.
*коза. Т. 8-927-402-60-91.
*памперсы №3, №5; кресло-коляска прогулочная (для взрослых), новая, дешево. Т. 8-927-248-06-29.
*говядина по частям, 250 руб./кг. Т. 8-927-463-63-17.
*летняя резина с дисками R-15 (б/у), мухобойка для капота (новая) на «Хундай Солярис». Т.: 8-927-404-35-02, 8-987-185-96-40.
*потроха гусиные. Т. 8-929-726-57-63.
*пчелосемьи. Т. 3-92-49.
*пчелосемьи. Т.: 8-937-528-78-69, 8-927-677-87-41.
*бараны, овцы на мясо. Т. 8-927-766-94-17.
*вощина ульяновская, 420 руб./кг. Обмен на воск. Т. 8-927-751-61-46.
*бычки (молодняк) от 2 до 5 месяцев. Т. 8-927-870-58-98.
*картошка (250 руб.), самовывоз. Т. 8-927-459-13-70.
*корова. Т. 8-937-293-57-01.

## РАЗНОЕ

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**
***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**
*Жалюзиның барлык төрләре, тиз. Т. 8-927-672-01-17.
*Электр монтажлау эшләре. Т. 8-937-614-70-15.
*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.
*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.
*грузоперевозки, «ГАЗель». Т. 8-987-413-96-70.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-419-56-48.
*грузоперевозки, «ГАЗель», 4 м, 15 куб. Т. 8-927-247-12-61.
*копаем и чистим колодцы, вручную. Т.: 8-929-723-88-60, 8-986-711-25-30.
*копаем, чистим колодцы. Т. 8-927-481-51-72.
*домашний электрик. Т. 8-917-936-20-96.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-247-93-50.
*ремонт холодильников. Т.: 8-937-610-58-78, 2-71-69.
*грузоперевозки «ГАЗель», 4,20, тент. Т. 8-927-442-38-10.
*услуги погрузчика, "КамАЗа". Т. 8-927-404-92-21.
*кухни и шкафы-купе на заказ, недорого. Т. 8-927-241-26-41.
*Нурлат-Самара (из дома), 350 руб. Т. 8-927-673-79-46.
*качественный ремонт квартир под ключ. Т. 8-937-773-98-04.
*ремонт компьютеров. Т. 8-927-474-71-20.
***кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.**
*ремонт стиральных машин на дому. Т. 8-927-672-56-28.
*все виды отделочных работ. Т. 8-937-620-00-60.
*ремонт, настройка компьютеров, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-0051-451.

**АЯК КИЕМНӘРЕН РЕМОНТЛАУ**
**22 АПРЕЛЬДӘ**
**9.00-18.00** сәг.тә
**Көнкүреш хезмәтләре күрсәтү йортында**
*(Мәктәп ур., 8)*
**КИРОВ**
**АЯК КИЕМНӘРЕ ФАБРИКАСЫ**
**аяк киемнәрен ремонтка кабул итә.**
*Алдан түләргә кирәкми.*
Аяк киемнәрегезгә
ИКЕНЧЕ ТОРМЫШ бүләк итегез.

**ТЕПЛИЦЫ**
**оцинкованные и окрашенные от производителя.**
Т.: 8-927-443-64-20,
8-927-245-01-90

## Искә алыгыз!



Сөекле, газиз улыбыз **Руслан Илһам улы ГЫЙЗЗӘТУЛЛИННЫҢ** 19 апрельдә туган көне. Үзе исән булса, аңа 23 яшь тулыр иде.
Ходаем, кадерлебезнең караңгы гүрләрен якты итеп, урынын оҗмах түрләреннән булдырсаң иде. Безнең бердәнберебезне белгән барлык кешеләр бу көнне аның рухына дога кылып искә алса, рәхмәтле булыр идек.

**Әнисе, әтисе, энесе.**

**ЭТАЛОН**
**ОКНА ДВЕРИ ЖАЛЮЗИ**
**ВОРОТА АРКИ РОЛЬСТАВНИ**
Замер, доставка - **БЕСПЛАТНО**
**ДОСТУПНЫЕ ЦЕНЫ**
**Рассрочка 0%** (без участия банка).
**Кредит** предоставляется АО "ОТП Банк"
**тел.: 2-02-50; 8-927-428-84-33**
Адрес: ул. Кооперативная, д. 1
(бывший ресторан «Колос», вход со двора)

## ТРЕБУЮТСЯ

*водители на хлебовозку, лаборант. Т. 8-927-417-62-73.
*семья снимет чистую 2х комнатную квартиру в районе 9-ой школы. Т. 8-937-773-98-04.
*разнорабочие. Т.: 8-927-442-66-12, 8-927-442-63-23.
*водитель категории «Е». Т. 8-927-405-21-61.
*ЗАО «Нурлатский элеватор» на постоянную работу медицинский работник (ца). Т. 2-00-28.
*на постоянную работу бригада штукатуров-маляров, сантехников. Т. 9-50-52.

**АДВОКАТ**
Барлык мәсьәләләр буенча юридик консультация.
Дәгъва гаризалары, шикаятьләр әзерләү.
ДТП буенча страховканы алу.
Алиментлар, бүлешү, аерылышу, мирас, хезмәт, пенсия, җир, торак мәсьәләләре.
Җинаять, гражданлык, административ эшләр буенча яклау.
**Т. 8-927-031-21-91.**

**Кафе «АЙГУЛЬ»**
*с вами и в радости и в горести.*
*Свадьбы, банкеты, дни рождения, поминки.*
*Ежедневно вас ждут вкусные завтраки, обеды, ужины, а также всегда свежая выпечка.*
**Наш адрес: ул. Салимжанова, 25 (территория продрынка).**
**8-927-414-34-79.**

**КОЕЛАР БОРАУЛАУ.**
**РАЙОН БУЕНЧА КОЕ БОЖРАЛАРЫН КИТЕРЕП БИРҮ – ТҮЛӘҮСЕЗ.**
**Т. 8-9274-233-978.**

**ТЕПЛИЦЫ ОТ ЗАВОДА,**
**ЛЮБЫХ РАЗМЕРОВ.**
**ТЕПЛИЦА**
**3Х6 - 15800.**
**Т. 8-929-722-29-89.**

**ЖАЛЮЗИ.**
8(84345) 2-02-50,
8-927-428-84-33.

12+ **"ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә**

**20 АПРЕЛЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**22 АПРЕЛЬ**
"Нурлат хәбәрләре",
"Татнефть" хәбәрләре.

**24 АПРЕЛЬ**
"Нурлат хәбәрләре".
"Сиңа дигән җырым", музыкаль тапшыру

Программалар **19** сәгатьтә башлана. **21, 23, 25** апрельдә иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

**Требуется водитель с категорией «D» на манипулятор.**
**8-927-032-49-83.**

**Требуется водитель с категорией «D».**
8-927-032-49-83.

## СДАЮТСЯ

*Тәүлекләп яки сәгатьләп фатир, командировкадагыларга. Т. 8-927-456-05-69.
*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.
*1-комнатная квартира. Т. 8-937-593-98-12.
*в аренду магазин 279 кв.м (возле д/с «Сказка»). Т. 8-917-251-93-15.
*квартира. Т. 8-927-412-39-30.

## КУПЛЮ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.**
*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-443-05-43.
*Йорт, документлары белән, 100 меңнән кыйммәт булмасын. Т. 8-960-837-49-31.
*видеомагнитофоны советские, платы, радиодетали. Т. 8-960-822-72-75.
*3-комнатную квартиру в р-не ул. Ленинградская, мкр. 50 лет Победы, инд.отопление. Т. 8-9274-18-94-60.
*1-комнатную квартиру, недорого. Т. 8-927-434-21-09.

## ПОТЕРИ

*утерянное свидетельство о регистрации серии ВИ №257928 на трактор «Versatile 2375» гос. номер 17-04 ЕР считать недействительным.

**«Классик» ОЦМПсы САТА:**
*Цинкланган, буялган, ташка һәм агачка охшаш* **ПРОФНАСТИЛ.**
*С-10, С-21, МП-20, Сс-10, СШ-10, С-8, НС-35.*
**МЕТАЛЛ ЧИРӘП:**
*«Супермонтерей», «Адамант», «Каскад»,*
**МЕТАЛЛ САЙДИНГ:**
- *«Корабельная доска»*
- *«Блок-хаус»*
- *«Софит»*

**ЕВРОРӘШӘТКӘЛӘК.**
**СУ АГЫП ТӨШҮ СИСТЕМАЛАРЫ.**
**ДОБОР ЭЛЕМЕНТЛАРЫ.**
**Заказга теләсә нинди төрдәге почмаклар.**
*Бәяләр - җитештерүче заводныкы.*
**Нурлат, Завод тыкр., 1А**
*(ЖБИ каршында).*
**(884345)2-54-00, 8-9276-778-776.**
Реклама

**«УЮТ МАСТЕР» компаниясе 100дән артык төстәге теләсә нинди катлаулылыктагы тарттырылма түшәмнәр тәкъдим итә.**
320 сумнан башлап
**Т. 8-927-246-52-50.**

